ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 27 сентябре
№ 60-VII ДС

проект
Татарстан Республикасы Дәүләт
Советы депутаты А.Г. Хәбибуллин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 92 (I өлеш), № 95 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 47 (I өлеш), түбәндәге эчтәлекле $3^1$ өлеш өстәп, үзгәреш кертергә:

«$3^1$. Муниципаль берәмлек уставында муниципаль берәмлек вәкиллекле органының җирле администрацияне формалаштыруда, шул исәптән җирле администрация башлыгы урынбасарларын, җирле администрациянең тармак (функциональ) һәм (яисә) территориаль органнары җитәкчеләрен вазыйфага билгеләүне раслауда яисә килештерүдә катнашу, шулай ук мондый катнашуның рәвешләре һәм тәртибе каралырга мөмкин.».

**2 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 3

(I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 47 (часть I), 3 нче кушымтаның 3.2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3.2.5. башкарма комитет җитәкчесе урынбасарларын, башкарма комитетның тармак (функциональ) һәм территориаль органнары җитәкчеләрен вазыйфага билгеләп куя һәм вазыйфадан азат итә, үз урынбасарлары арасындагы йөкләмәләрне бүлә, муниципаль хезмәткәрләрне һәм башкарма комитетның башка хезмәткәрләрен вазыйфага билгеләп куя һәм вазыйфадан азат итә, аларның эшчәнлеген тикшереп тора, аларга карата кызыксындыру чаралары һәм дисциплинар җаваплылык чаралары куллана (башкарма комитет җитәкчесе урынбасарларын, башкарма комитетның тармак (функциональ) һәм (яисә) территориаль органнары җитәкчеләрен вазыйфага билгеләү муниципаль берәмлек уставы нигезендә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы белән килештереп башкарыла).».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

Закон проекты җирле үзидарә турындагы республика законнарын федераль законнарга кертелгән үзгәрешләргә туры китерүгә юнәлдерелгән.

Мәсәлән, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 37 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2024 елның 22 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль берәмлек уставында Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә муниципаль берәмлек вәкиллекле органының җирле администрация формалаштыруда катнашу, шул исәптән җирле администрация башлыгы урынбасарлары, тармак (функциональ) һәм (яисә) территориаль органнар җитәкчеләрен вазыйфага билгеләүне раслауда яисә килештерүдә катнашу хокукы каралган.

Әлеге Федераль закон проекты нигезендә күрсәтелгән хокукны муниципаль берәмлек уставы белән билгеләү мөмкинлеге карала.

Бер үк вакытта закон проекты белән башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасына билгеләп куела торган зат белән төзелә торган контрактның үрнәк рәвешенә үзгәрешләр кертелә (Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына 3 нче кушымта).

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.